**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

29 октябрь 2021 ел № 85 Урыссу ш. т. п.

2022 елга Ютазы муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның
Фаразланган планын (программасын) раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, "Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендә кабул ителгән 178-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2008 ел, 30 май, 115 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында» гы Нигезләмәгә, “Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 94 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. 2022 елга Ютазы муниципаль районының күчемсез милкен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) кушымтага ярашлы расларга.

2. Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2022 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеген хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) тормышка ашыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм авыл җирлекләре советлары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы

вазыйфаларын башкаручы З. В. Ильясов

Татарстан Республикасы
Ютазы район Советының
29.10. 2021 ел № 85 карары
белән расланды

**2022 елга "Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкен ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫҢ ФАРАЗЛАНГАН ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)**

**I бүлек. 2022 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыру бурычлары**

2022 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) 21.12.2001 елдагы "Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" Федераль закон , 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, "Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 22.07.2008 ел, № 159-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2008 елның 30 маендагы 115 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында» гы Нигезләмә нигезендә эшләнде.

Муниципаль милек белән идарә итүнең базар икътисады шартларында формалаша торган системасы өлеше буларак, 2022 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыруның төп бурычлары «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль милек структурасын оптимальләштерү, шулай ук «Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 159-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен тормышка ашыру, 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендага ала торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" гы Федераль закон таләпләрен үтәү тора.

2022 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан район бюджетына салым булмаган керемнәр кертүне тәэмин итү;
- бюджетның керем өлешен арттыру;
- милекне карап тотуга район бюджетыннан чыгымнарны киметү.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге икътисадында хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә түбәндәге сәбәпләр аркасында структур үзгәрешләр көтелми:

- хосусыйлаштыру өчен тәкъдим ителгән торак булмаган бүлмәләрдә милекче алышынганда муниципаль берәмлектәге икътисади хәлгә сизелерлек йогынты ясый ала торган производство урнаштырылмый;

Мөлкәтне сату хисабына район бюджетына якынча 350 мең сум акча алу планлаштырыла.

Хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) нигезендә сатуга планлаштырылган объектның якынча бәясе базар бәясен үткәргәннән соң төгәлләштерелергә тиеш.

Хосусыйлаштырылырга тиешле объектның фаразланган бәясе базарның килеп туган конъюнктурасыннан чыгып исәпләнә.

2022 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган мөлкәт Исемлеге муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

## II бүлек. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2022 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль милке

| № т/б | объект | адрес | Хосусыйлаштыру ысулы | Күздә тотылган гамәлгә ашыру вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Гомуми мәйданы 76,8 кв. м, кадастр номеры 16: 43: 100119:1454 булган торак булмаган бүлмәләр | Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы,Урыссу ш.т.п., Ленин ур., 14 | ачык аукцион | 2 квартал | |